## Котлыйбыз !

Кадерле ир-егетләребез, сезне иң җылы хисләр, Җир йөзендәге иң матур теләкләр аша элек-электән килгән бәйрәм - Ватанны саклаучылар көне белән тәбрик итәбез. Бу көндә сезгә саулык, озын гомер, нык сәламәтлек, һәрвакыт якыннарыгызның күңел җылысын, кешеләрнең хөрмәтен тоеп яшәвегезне, йөргән юлларыгыз якты булуын, күңелегездә матурлык, йөрәгегездә шәфкатьлелек нуры сүнмәвен, янадан-яна уңышларга ирешүегезне телибез. Бәйрәм белән сезне, хөрмәтле ир-егетләр!




## Тынычлык

Тынычлык - ул барлык халыкның
Дус һәм тату яшәү үрнәге.
Җир йөзендә яше – картының
Тынычлык дип тибә йөрәге.

Тынычлык яшәсен дөньяда,
Тыныч булсын шәһәр, авыллар.
Кабынмасын террор утлары,
Көчәймәсен җирдә давыллар.

Аяз күк йөзендә елмаеп
Сипсен кояш алсу нурларын.
Сыкрамасын әти – әниләр
Сугышта югалтып улларын.

Тыныч аксын чишмә сулары,
Болганмасын диңгез – дәрьялар.
Тыныч булсын иде җир шары,
Тыныч булсын иде дөньялар.

Елмаеп уяныйк йокыдан,
Тигез итеп алып сулышны.
Кулга кул тотынып дус яшик,
Кабындырмыйк җирдә сугышны !

Шартламасын иде бомбалар,
Берләшсеннәр дуслык, тынычлык.
Илнең иминлеген сакларга
Кирәк бездән бары тырышлык.

Тыныч күңел, шат елмаю белән
Тырышып укырбыз мәктәптә.
Яшәсен дуслык һәм тынычлык!
Калыйк һәрчак шушы теләктә.

*Фәттахова Зәлидә,*
*Лесхоз мәктәбе укучысы.*

**Ял сәгатьләрендә**




**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
**Дәүләтьярова Ләйлә Гилмулла кызы**
**Редколлегия әгъзалары: Садыкова Г.Р., ГыйләҗиеваГ.Х., Рәхимҗанова Ә.М., Габдрахманова Л.М.,Хисматуллина В.Б., Йосыпова Р.К.**

**Индекс-** 422000
**Тираж-** 100 данә

**Адрес:** ТР,Арча шәһәре, Вагыйзовлар урамы, 11
Арча муниципаль районы"Арча мәгариф идарәсе"



# ЧИШМӘ БАШЫ

" Туган телне сөючеләр"пресс-центры
Февраль, 2016 ел
№2

### *Бу санда*

- ✓ Сәләтеңә канат куй !
- ✓ Җырдай моңлы туган тел
- ✓ Үлемне җиңгән шагыйрь
- ✓ Мәктәп сулышы
- ✓ Бөек шагыйребез Г.Тукайның туына-130 ел
- ✓ Иҗат – гүзәл гамь ул

### *Февраль аенда истәлекле даталар*



**15 февраль- Советлар Союзы Герое , шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 110 ел (1906-1944)**

**21 февраль - Халыкара Туган тел көне**

**23 февраль – Ватанны саклаучылар көне**



**28 февраль – шагыйрә Шәмсия Җиһангировага 65 яшь**

## 21 февраль – Халыкара туган тел көне

Берләшкән Милләтләр оешмасы (БМО) карары буенча 21 нче февраль Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә. 1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте. Беренче мәртәбә ул 2000 елның 21 нче февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

Ни өчен Халыкара туган тел көне итеп 21 февраль билгеләнгән соң? Эш шунда: 1952 елның 21 нче февралендә Пакыстанда банглы теленә дәүләт теле статусы таләп итеп көрәшкән 5 студент үтерелгән була. Билгеле булганча, Пакыстанның көнчыгыш өлеше соңрак Бангладеш бәйсез дәүләтенә әйләнә. ЮНЕСКО Халыкара туган тел көнен билгеләп үтүне хуплап чыга.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд. кеше сөйләшә; инглиз телендә — 478 млн, хинди телендә — 437 млн, испанда — 392 млн, рус телендә — 284 млн, гарәптә — 225 млн, португалда — 184 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

Галимнәр планетабызның теләсә кайсы кешесе белән аралашу өчен, 14 телне белү җитә дип саный. Болар бенгал (Бангладеш), гарәп, инглиз, испан, итальян, кытай, немец, португал, урду (Пакистан), урыс, француз, һинд һәм япон телләре. Шулар арасында татар теле дә бар.

Татар теле дөньядагы дәрәҗәле 14 телнең берсе икән. Татар телен белгән кеше 30 дан артык төрки халык белән җиңел аңлаша һәм аралаша ала.

Безнең туган телебез-татар теле Россиядә рус теленнән кала икенче урында тора. Татарларның 80% Россиядә яши.

100меңе-төньяк Кавказда,
40меңгә якын -чит илләрдә
Төркиядә -25 меңләп
Кытай һәм Польшада -5әр меңләп татар яши.



# Без- Тукайлы халык

*Укып, балалар алга баралар...*

- ***Очып төш тә балалык бишегеннән, ябыш- аерылма мәктәп ишегеннән...***
- ***Синең бу барган юлың – галимнәр юлы; бу юл белән барлык олы кешеләр җитешкән.***
- ***Максаты - иксез – чиксез бәхет; соңы – үсү, бөеклеккә күтәрелү...***
- ***Мәгариф – хәяттер. Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне... Мәгарифтән генә көтмәк кирәктер.. Укып, балалар алга баралар...***

*Г. Тукай*

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан һәм, әлбәттә, аның дөнья мәдәниятенә керткән өлеше алдында баш ию, исемен , иҗади мирасын мәңгеләштерү максатында бу уку елында милли тәрбия бирүне Г.Тукай шәхесе һәм аның иҗатына багышлыйм.

Тукай – педагог та. Аның татар мәктәбе үсешенә керткән төп яңалыгы – татар әдәби теленә нигез салуы һәм аны мәктәптә төп укыту теле буларак тәкъдим итүе белән билгеләнә.Татар мәктәпләре өчен дәреслек-кулланмалар язуы да Г.Тукайны атаклы педагоглар рәтенә куярга мөмкинлек бирә. Ә инде гасырдан артык вакыт эчендә татар балаларын тәрбияләүдә кулланылып килгән күпсанлы шигырь, поэма, әкиятләрен дә мисалга китерсәк,фикернең дөреслеге тагын бер кат раслана. Әмма Г.Тукай теоретик педагог кына булып калмый, мөгалимлек эше белән дә шөгыльләнә. Ул – татар теленең чисталыгы, халыкчанлыгы өчен көрәшүчеләрнең дә иң сафында була. Моны ул гади телдә язылган дәреслек- кулланмалары белән раслады. Автор тарафыннан туган телгә карата булган җаваплылык, шулай ук әсәрләрнең аңлаешлы, чиста телдә язылган булулары белән дә, үзләренең тәрбияви яктан көчлелеге белән дә игътибарны җәлеп итәләр. Алар бүгенге көндә дә заманча яңгырыйлар. Алардан тормышның барлык сорауларына да җавап табарга, киңәш алырга була. Иң мөһиме : аны кадерләп, яратып һәм аңлап укырга гына кирәк, нәни дустым!

Бөек татар шагыйренең тууына 130 ел тулуны билгеләп үтү милли мәдәниятнең иң мөһим вакыйгаларының берсе генә түгел, ул шагыйрьнең иҗади мирасын өйрәнүгә көчле импульс та.

*Ә.М. Рәхимҗанова , Урта Пошалым төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## “ Язмышларга буйсынмас җан”

Мәктәптә “ Язмышларга буйсынмас җан “ исемле класс сәгате уздырылды. Тормышка мәхәббәт, яшәү көче, батырлык турында матур әдәбиятта күпме гүзәл әсәрләр иҗат ителә. Безгә табигать кочагында яшәү, ил, дөнья буйлап сәяхәттә йөрү, кешеләр белән теләгәнчә аралашу – зур бәхет, әлбәттә. Ләкин әле бәхетнең башка төрлесе бар. “ Язмыш синең тез астыңа китереп сукса, егылмас өчен ябыш. Утларга салса – үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа, күбек булып өскә күтәрелмә - асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңы күреп чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә - яңгыр тамчыларына кушылып җиргә төш. Түземнәр генә бәхеткә лаек,” – дип яза Ф. Яруллин үзенең “Җилкәннәр җилдә сынала” дигән әсәрендә.

Менә шундый корыч ихтыярлы, олы җанлы, көчле рухлы язучыларыбызның берсе – Муса Җәлил һәм Г. Тукай исемендәге премияләр лауреаты Фәнис Яруллинның- хөрмәтле язучыбызның тәрҗемәи хәле белән тагын бер кат таныштык. Аның күпкырлы шәхес- шагыйрь, прозаик, журналист һәм драматург өлкәсендәге иҗатын барладык. Класс сәгатенең эпиграфы итеп, “Каерса да язмыш минем канатымны, Ала алмас кешеләрне яратуны”,- дигән юллар алынды.Укучылар язучының бик күп әсәрләрен сәнгатьле итеп укыдылар. Дәрес ахырында “Язмышларга буйсынмас җанлы” шагыйрьнең китапларын әле күп тапкырлар хөрмәт белән кулга алып, тормыш авырлыклары белән очрашканда, аледән - әле аның шигъри юлларына мөрәҗәгать итәләр әле дип уйлады һәр укучы күңеле.

*В.Б.Хисматуллина, Иске Кырлай төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*



## Герой килде...

22 нче февраль көнне Казанбаш төп мәктәбендә Ватанны саклаучылар көненә багышланган зур бәйрәм үткәрелде. Бәйрәмгә Мәскәү шәһәреннән Россия Герое полковник Сафин Дмитрий Анатольевич, Арча шәһәреннән “Сугышчан туганлык” исемле әфганчы сугышчылар җәмгыяте җитәкчесе Баһаветдинов Сергей Лимусович, әфган сугышы хәрәкәтләрендә катнашкан Гарипов Рафис, Шакирҗанов Дамир, Тимашев Фәнис, Чечен Республикасында хәрби бурычын үтәгән авылдашларыбыз Заһриев Рөстәм, Гобәйдуллин Илгиз, Латыпов Рәшит, Исмәгыйлев Ирек, Әсхәдуллин Илшат килде. Бәйрәмгә шулай ук барлык әтиләр дә чакырылды. Кунаклар мәктәп белән таныштылар һәм музейда булдылар.

Иң беренче сүз полковник Сафин Дмитрий Анатольевичка бирелде. Ул укучыларыбызны хәрби хезмәт һөнәре белән таныштырды. Укучыларда Ватанны ярату хисләре тәрбияләү максатыннан Баһаветдинов Сергей Лимусович укучыларны тырышып укырга, кыю булырга чакырды. Шакирҗанов Дамир, Заһриев Рөстәм, Тимашев Фәнис тә укучыларга үзләренең теләкләрен житкерделәр, Ватанны лаеклы саклаучылар булып үсүләрен теләделәр.

Укучылар килгән кунакларга зур концерт күрсәттеләр. Бәйрәм чарасы спортзалда дәвам итте. “Әти-әни һәм мин – спорт сөюче гаилә” дип аталган спорт бәйгесе үткәрелде. Бәйгедә өч гаилә катнашты. Гаиләләр үзләренең көчле, житез булуларын, спортны яратуларын расладылар. Бәйрәм һәркем күңеленә хуш килде. Укучыларга бик файдалы патриотик тәрбия чарасы булды.

*Л.М. Габдрахманова., Казанбаш төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Кышкы уйлар**

Кемдер ярата эссе җәйне
Мин яратам салкын кышларны.
Күзәтергә яратам агачларга кунган
Песнәкләрне, кызылтүшләрне.
Яратам бәс сарган куакларны,
Битне чеметтергән буранны.
Күкрәк тутырып сулап әйләнәмен
Кар көртләре баскан урамны.
Ап- ак карлар ява җиһанда
Бөтерелеп куна битләргә.
Әйтерсең лә зәңгәр күктән
Коелалар якты йолдызлар.

***

Салкын кышлар артта калып бара,
Җылы хәзер инде иртәләр.
Яз сулышы сизелә һәр тарафта,
Күктән кояш карый иркәләп.
Тиздән боз кузгалыр елгаларда,
Яз сулышын өрер кырларга.
Моңлы җырын сузып кошлар кайтыр,
Сагынышып туган илләргә.

**Туган авылым**

Яратам мин туган авылымны,
Карамыйм да борылып шәһәргә.
Тәмле суы, саф һавасы аның
Көч- дәрт бирә миңа яшәргә.
Туган авылымның күгендә
Яна кебек ай да яктырак.
Көмеш сулы чишмәләре,
Болыннары җанга якынрак.
Авылымны ямьләндереп тора
Иман йорты- мәчетләр.
Моңлы азан тавышлары
Иминлек тели таңнан.

**Җиңү язы**

Менә тагын ямьле язлар килде,
Шат авазлар яңгырый җиһанда.
Җиңү язы килгән елны
Хәтерләтә алар күпләргә.
Җитмеш ел вакыт узып киткән,
Тыныч көннәр илемә килгәнгә.
Яуда калган батырларның сәламнәрен
Кошлар алып кайтыр язларда.

*Бакыева Илүзә,*
*Казанбаш төп мәктәбенең*
*7 сыйныф укучысы*

**Чыршы зары**

Агачта кеше язмышы.
Аңласын кеше барын.
Мин сөйлимен, тыңлагыз
Чыршы агачы зарын.
Урманда үсте
Чыршы агачы.
Күзәтеп йөрде
Авыл агасы.
Бәйрәм алдыннан
Урманга барды.
Кулына үткен
Балтасын алды.
Тып-тын урманда
Ап-ак кар ява
Мескен чыршыкай
Сулкылдап ава
Алып кайттылар,
Бизәп куйдылар.
Бәйрәм үткәч тә
Аннан туйдылар.
Чыгарып аттылар
Чүплеккә аны.
Рәнҗеде чыршы,
Сыкрады җаны.
Бер көнлек кызык өчен
Кыймагыз сез җаннарны.
Утыртыгыз ,үстерегез,
Саклыгыз сез аларны!
Ясалма чыршылар бит
Кибетләрдә сатыла.
“Табигатьне саклагыз!’’-дип
Дәшәм яше-картына.

**Тукай абый.**

Моннан бик күп еллар
Яшәсә дә ул элек.
Тукайны бәләкәйдән
Үсәбез бит белеп.
Яңа туган балаларга
Бишек җырын көйлиләр.
Үсә төшкәч сабыйларга
Әкиятләрен сөйлиләр.
Тукай абый әсәрләре
Яхшылыкка өйрәтә.
“Су анасы”н, “Шүрәле”не
Яратабыз бигрәк тә.

*Арсаева Зөһрә,*
*Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең*
*7 сыйныф укучысы*





**Марат – зур бүләк иясе!**

8 февраль көнне Арча муниципаль район җитәкчесе И.Г. Нуриев республика олимпиадаларында җиңү яулаган укучыларны һәм аларның остазларын бүләкләде. Бу мактаулы бүләккә безнең мәктәптән 10 сыйныф укучысы Зиннатов Марат һәм укытучы С.Ә.Корбанова лаек булды. Марат экология фәне буенча үткәрелгән Бөтенрәсәй олимпиадасының республика этабында призлы урын яулады. Маратка алга таба да зур уңышлар телибез.

*Миләүшә Гәләветдинова, Лесхоз урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы.*



**Афәрин , кызлар !**

Лесхоз урта мәктәбенең 9нчы сыйныф укучылары Гарипова Зәлидә һәм Евсеева Вера татар теле фәне буенча республика олимпиадаларында катнаштылар. Нәтиҗәдә Вера – җиңүче, ә Зәлидә призлы урынга лаек булды. “Белемле меңне егар..” дигән мәкаль кызларыбызга бик туры килә. Афәрин, кызлар !

*Л.Г. Дәүләтьярова, Лесхоз урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Аделина белән горурланабыз!**

Казанбаш төп гомуми белем мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы Гатиятуллина Аделина татар теленнән республика олимпиадасында катнашып призлы урын яулады. Халыкара олимпиадада икенче турга үтеп финал ярышларында катнашуга иреште безнең Аделина. Аңа уңышлар телибез.

*Л.М. Габдрахманова, Казанбаш төп мәктәбе нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Музыка сәнгате өлкәсендә уңышлар**

Сәнгать мәктәбе филиалының музыка уен кораллары түгәрәгенә йөрүче укучылар Республика буенча оешты - рылган **Mira-Bella** халык-уен кораллары фестиваль-конкур-сында катнаштылар. 5 нче класс укучысы Харисов Айбулат, Ситтиков Булат , 6 нчы класс укучысы Гыйлаҗиев Рамил, гран-прига ия булдылар. Җитәкчеләре Харисов Рәдис Рафисовичка рәхмәтебезне җит - керәбез. Укучыларның сәнгатьтә югары баскычларга ирешүләрен телибез.

*Г.Н. Муллагалиева ,Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*



**Уңышлар сиңа, Диләрә !**

Төбәгебез татарның атаклы шәхесләрен күпләп биргән. Без моның белән горурланабыз. Шуларның берсе астроном, фәлсәфәче һәм мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси. Быел аның туына 160 ел. Шул уңайдан, Гәрәфиева Диләрә күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган XI республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясенә якташыбыз турында фәнни эш башкарып, II турга узды. Диләрәгә һәм фәнни җитәк - чеәре Рәхимҗанов Ф.Ф, Рәхимҗанова Ә.М зур уңышлар телибез.

*М.З.Ильясов, Урта Пошалым төп мәктәбе директоры*

# Сәләтеңә канат куй !

## Сәләтле балалар - безнең киләчәгебез

Шаулап үскән агачта күпме яфрак бар?! Яфракларны бер-берсе белән чагыштырып карасак, ике бертөрле яфрак таба алырбызмы? Алар бер-берсеннән формасы, зурлыгы, төсе һәм башка бик күп сыйфатлары белән аерылып торалар. Бер агачта бертөрле ике яфрак таба алмаган кебек, җир шарында ике бертөрле кеше дә таба алмабыз. Хәтта тышкы кыяфәтләре белән бик охшаш игезәкләр дә бер-берсеннән күптөрле сыйфатлары белән аерылып торалар. Әлеге мисаллардагыча, балаларның да акыл үсеше, фикерләү дәрәҗәсе, рухи дөньясы, психик һәм физиологик халәте, эчке кичерешләре, теге яки бу эшкә сәләте дә бер үк дәрәҗәдә түгел, һәр кешенең үз кимчелекләре һәм үз өстенлекләре бар, һәр шәхес үзенчәлекле һәм кабатланмас.

Шушы үзенчәлекләр яңа мәктәп шартларында иҗади фикер йөртүче педагогларны укучыларга белем бирү генә түгел, ә аларның табигать тарафыннан бирелгән сәләтләрен дә үстерүне максат итеп куя. Укучы бала мәктәпкә белем артыннан гына түгел, төрле яклап сәләтен үстерер өчен дә килә. Укытучыдан сәләтле балаларның күңелен аңлау, аларның үсешенә көч-куәт бирерлек эшләр башкару, индивидуаль якын килү таләп ителә.

Хәзерге заман таләбе - баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес итеп тәрбияләү. Белгәнебезчә, укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү - хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз.

Һәр баланың нинди дә булса сәләте бар. Яңа мәктәп шартларында андый балаларны күрә һәм сәләтен үстерү өчен шартлар булдырырга, ярдәм кулын сузарга кирәк. Шул чакта гына бала үзен кабатланмас шәхес итеп тоя, үзенең мөмкинлекләрен, эш–гамәлләрен аңлый һәм бәяләргә өйрәнә. Шул вакытта сыйныфташлары һәм укытучы тарафыннан аңа шәхес буларак ихтирам формалаша.

Сәләтле балаларны һәрьяклап үстерү өчен мөмкинлекләр аз түгел. Казан федераль университеты мөгаллимәләре үзләре килеп һәм skype ярдәмендә районыбыз мәктәпләреннән сәләтле укучыларны туплап татар теле һәм әдәбияты фәнен тирәнтен өйрәнү буенча дәресләр үткәрәләр.

Алар белән тыгыз элемтәдә эшләүнең нәтиҗәсе бар. Татар теле һәм әдәбияты фәне буенча Республика күләмендә үткәрелгән олимпиадада укучыларыбызның зур уңышларга ирешүе дә аларның тынгысыз хезмәт нәтиҗәсе: Валиуллина Раилә - татар әдәбиятыннан призер (Яңа Кенәр урта мәктәбе, 11 нче сыйныф, җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы -Габдрахманова И.М.), Васильева Инзилә - татар теленнән призер (Сеҗе төп мәктәбе, 9 нчы сыйныф, җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Җәләлиева Г.И.), Гатиятуллина Аделия - татар теленнән призер (Казанбаш төп мәктәбе, 6 нчы сыйныф, җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Исхакова Ф.Ш.), Кәримова Алинә – татар теленнән призер (Шушмабаш урта мәктәбе, 6 нчы сыйныф, җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сабитова Т.А., Мортазина Гөлүсә - татар теленнән призер (Курса Почмак урта мәктәбе, 11 нче сыйныф, җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гыйбадуллина Г.М.), .

Рус мәктәбендә укучы татар балалары һәм рус балалары арасында көрәш кызу булды. Укучыларыбыз монда да сынатмадылар, районыбызга югары нәтиҗәләр белән кайттылар: Гибаева Зилә - татар теленнән призер (Иске Чуриле мәктәбе, 7 нче сыйныф, җитәкчесе: Хәйруллина Г.Р.), Гарипова Зәлидә татар теленнән-призер (Лесхоз урта мәктәбе, 9 нчы сыйныф, җитәкчесе: Дәүләтъярова Л.Г.), Ризванова Камилә - татар теленнән призер (Арча 5 нче номерлы гимназиясе, 10 нчы сыйныф, җитәкчесе: Газизова Э.И.), Мубаракшина Чулпан – татар әдәбиятыннан призер (Арча 2 нче номерлы урта мәктәбе, 9 нчы сыйныф, җитәчесе: Насыйбуллина Г.Р.), Нургалиев Айнур - татар әдәбиятыннан призер, ( Арча 5 нче номерлы гимназиясе, 10 нчы сыйныф, җитәкчесе: Гилязиева Л.Ф.), Васильев Кирилл-татар теленнән призер (Иске Чуриле мәктәбе, 7 нче сыйныф, җитәкчесе: Хөсәенова Р.Д.), Евсеева Вера- татар теленнән җиңүче (Лесхоз урта мәктәбе, 9 нчы сыйныф, җитәкчесе: Дәүләтъярова Л.Г.), Кузьмичева Регина - татар теленнән призер (Арча 2 нче номерлы урта мәктәбе, 11 нче сыйныф, җитәкчесе: Нәбиуллина Ф.Х.).

Тырышып, үз эшеңне чын күңелдән яратып, вакытыңны кызганмыйча эшләсәң, сәләтле балалар тагын да зур уңышларга ирешәчәк һәм калган укучылар арасында сәләтле балалар саны һичшиксез артачак, әлбәттә.

**Милли мәсьәләләр буенча методист Мостафина Энже Габдулатҗан кызы**



# Иҗат - гүзәл гамь ул

### Бөек Җиңү бәйрәме!

Дөньяны ямьләндереп
Матур яз килә безгә,
Май аенда гөрләп килә
Зур Бәйрәм илебезгә.

Иң хөрмәтле бәйрәм ул
Бөек Җиңү бәйрәме
Олыларны котлап без,
Бирик чәчәк бәйләме.

Алар күргән зур кайгылар,
Авырлыклар үткәннәр
Без рәхәттә яшәсен дип,
Бик күп каннар түккәннәр.

Хөрмәт белән искә алыйк,
Онытмыйк бу бәйрәмне
Яшик тыныч тормышта
Күрмик алар күргәнне!

*Гыйльмуллина Динә,*
*Лесхоз урта мәктәбенең*
*6 сыйныф укучысы*

### Очрашу

“ Сәлам”- дидем бер көнне
Таныш түгел кешегә.
Ул елмаеп җавап бирде:
“ Сәлам”- диде, кул бирде.
Кулын кыстым,
Өйгә таба юл тоттым.
Бу очрашу озак кына
Торды минем башымда.
Син дә елмаеп исәнләш
Очраган бер кешегә

*Хөсәенов Ильназ, Иске Кырлай төп мәктәбенең 5 сыйныф укучысы*

### Тукайга илтә уйларым.

Кулга каләм алдым исә,
Һәрчак Тукай төшә искә.
Каләмемне читкә куеп,
Ирек бирәм уйга, хискә.
Тормыш сукмакларын барлап,
Кушлавычка чыгып китәм,
Өчиле һәм Кырлайдан соң
Җаекка ук барып җитәм.
Кыска гомерле булуның
Сәбәпләрен эзлим шулай.
Тормыш йомгагын сүткәндә,
Ялгышып та куям бугай.
Әнисе Мәмдүдәгә дә
Кайчак минем хәтер кала.
Ничек ташлап китә алган?
Йөрәк парәсе бит- бала.
Өчиледә – артык кашык,
Кем ул ямщик арбасында?
Ни уйлады икән Тукай
Җиде ятлар арасында?
Йөрәгеннән чыккан сагыш
Шигъри юлга салынгандыр.
Буыннардан буыннарга
Күпме мирас калдырган ул.
Игътибар белән укыйм мин
Тукай язган һәрбер сүзне.
Чын кеше булып үсәргә
Өйрәткән бит алар безне.
Шигырьләренең мәгънәсен
Яхшырак аңлый барам.
Габдулла Тукай бөек, дим,
Һәм аннан үрнәк алам.

*Гаффарова Әнисә, Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең 9 сыйныф укучысы*

### ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ.

Бу дөньяда һәрбер бала
Гаилә назын тоеп үссен.
Җир йөзендә һәр баланы,
Тигез матур тормыш көтсен.
Ятимлекне һич белмәсен,
Гөлдәй нәфис сабый җаны.
Бер канаты әни булса,
Икенчесе әти аның.
Әти кулы терәк булса,
Әни кулы назга төрә.
Тигез гомер, тату гаилә,
Тормышларны ямьгә күмә.

*Шәрипов Марат, Казанбаш төп мәктәбенең 6 сыйныф укучысы*

# Мәктәп сулышы

## Ажаган уенының зона ярышлары

12 нче февраль көнне Лесхоз урта мәктәбендә “Ажаган” хәрби-патриотик уенының зона ярышлары булып узды. Ярышларда 11 команда көч сынашты: Лесхоз, Урта Пошалым, Казанбаш, Түбән Мәтәскә, Иске Кырлай,Түбән Аты, Утар Аты, Шушмабаш, Кушлавыч, 5нче номерлы гимназия,7 нче номерлы мәктәп командалары. Һәр команда төз ату, яралыга беренче медицина ярдәме күрсәтү, автомат сүтеп җыю буенча ярыштылар, “Азимут буенча хәрәкәт итү”,” Химзащита”, “Мина кыры” кебек конкурсларда үз көчләрен күрсәттеләр.Ярыш нәтиҗәләрен запастагы ветеран офицерлар союзы председателе Козлов Ю.П. житәкчелегендәге хөкемдарлар күзәтеп һәм бәяләп барды. Гомуми нәтиҗәләр буенча Лесхоз мәктәбе командасы беренче урынны яулады , икенче урында - 7 нче мәктәп , өченче – Иске Кырлай мәктәбе командалары. 1-2 урынга лаек булган командалар“Ажаган”ның Арча шәһәрендә узачак финал уеннарында катнашачаклар. Командаларга уңышлар теләп калабыз.

*Г.Р. Садыкова, Лесхоз урта мәктәбе укытучысы*



## Мәктәптә туган тел көне

“Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар,
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр.”

Туган тел. Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган «әни», «әти», «әби», «бабай» сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Туган-үскән ил-җирнең якынлыгын, Ватанның газизлеген без әүвәл туган тел ярдәмендә тойганбыз. Милләтебез сәнгать ияләренең матур-матур шигырьләрен ятлап әле дә куанабыз, рухланабыз. Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарих көзгесе. Шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы, аһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә, эшләргә кирәк. Менә шундый уйлар, матур теләкләр , күңелдәге иң изге хисләребез белән үткәрдек без мәктәптә “Туган тел” көнен.

*Фазлыева Илүзә, Иске Кырлай төп мәктәбенең 8 сыйныф укучысы*

## Гөж килеп алдык...

Февраль аенда истә калырлык вакыйгалар хәйран булды. Хәрби - патриотик айлык кысаларында мәктәптә күп кенә чаралар булып узды. Һәркем үзен җаваплы хис итеп, бу чараларны уздыру һәм катнашу теләге белән янды. Армрестлинг ярышында Махмутов Айнур һәм Нигматуллина Рамилә җиңү яуласа, турникта күтәрелү буенча Ибениев Раил һәм Сафин Ирекка тиңнәр булмады.
1-7 класслар арасындагы “Күңелле стартлар” һәм малайлар командалары арасындагы “Ягез әле,егетләр!” бәйгесе күпләрнең исендә озак сакланыр.

*Фәйрүзә Зиятдинова, Урта Пошалым төп мәктәбнең 8 сыйныф укучысы*



## Уңышлар сезгә, Мәннәновлар !

Бертуган Мәннәновлар кечкенәдән татарча көрәш белән мавыгалар. Башлангыч сыйныфларда укыган вакытта ук алар үз үлчәүләрендә алдынгы урыннарны алган көрәшчеләр. Мәктәп укучылары арасында үткәрелгән татарча көрәш ярышларында мәктәбебезнең 6 нчы сыйныф укучысы Мәннәнов Әлфис, 11 нче сыйныф укучысы Мәннәнов Фәнгиз әле дә үз авырлыкларында алдынгылыкны бирмиләр. Район башлыгы призына мәктәп укучылары арасында үткәрелгән ярышта Әлфис 1 урын, районнар арасында Балтачта үткәрелгән көрәштә үз үлчәвләрендә 2 урыннарны яуладылар.
Уңышлар сезгә, Мәннәновлар!

*Р.К. Йосыпова, Түбән Мәтәскә урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*



## Тукай иленә сәяхәт



19февраль көнне “ Халыкара туган тел көне” атналыгы кысаларында 4 класс укучылары Лесхоз китапханәсендә “Тукай иленә сәяхәт” дигән кичәдә катнаштылар. Укучылар Г.Тукайның иҗат һәм тормыш юлы турындагы белемнәрен ныгыттылар, шигырьләренә язылган музыкаль әсәрләр белән таныштылар, “Тукай эзләре буйлап” дигән презентация карадылар. Китапханәче Раушания Ибраһимовна укучыларны китапханәдә булган Г.Тукайның китаплары белән таныштырды. Кичә ахырында Тукай әсәрләре буенча викторина үткәрелде.

*Т.И. Шәймарданова , Лесхоз урта мәктәбе башлангыч сыйныф укытучысы*



## “Тукай эзләре буйлап” бәйгесенең нәтиҗәләре

Күренекле татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 130 еллыгы уңаеннан "Тукай эзләреннән" бәйгесе үтте. Бу бәйгедә безнең укучылар бик актив катнаштылар. Безнең мәктәптән 1 нче класс укучысы Якупов Рүзәл 2 нче (җитәкчесе Шиһабиева Л.Р.), Казиле башлангыч мәктәбеннән 1 нче класс укучысы Йөзлекәев Айназ 3 нче урын (җитәкчесе Арсаева Л.Р.) яулады.

*Х.К Сәгъдиева, Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Тукайга

Балачакта булган нәни Апуш,
Үсеп җиткән бөек Тукайга.
Туга көнең бәйрәм итә халкым,
Исемең яңгырый бүген һәркайда.

Зурлап искә ала сине бүген
Татар яши торган һәрбер ил.
Синең иҗатыңа хөрмәт булып
Гимн булып яңгырый “Туган тел”.

Укый алмагансың безнең кебек
Барлык шарты булган мәктәптә.
Компьютеры, интернеты да юк,
Телефон да булмаган хәтта.

Ә шулай да ятим бер сабыйга
Ходай сәләт биргән, күр әле.
Сокландыра безне Кисекбашы,
Су анасы белән Шүрәле.

Туган көнең белән котлап, Тукай,
Шигырь яздым синең турында.
Һәр әсәрең барыр мирас булып
Бездән соң да килгән буынга.

*Фәттахова Зәлидә, Лесхоз урта мәктәбенең 7 сыйныф укучысы*



## Габлулла Тукай

Тукай абый Габдулла
Танылган язучы ул.
“Шүрәле”,”Туган тел”,
“Пар ат”,”Су анасы”
Әсәрләрен язган ул.
Бик кыска булган гомере,
Ул да җиңел узмаган.
Авыр чакта, кайгырганда
Юатучы булмаган.
Аның мәсәл-әкиятләрен
Бик яратып укыйбыз.
Тукай кебек шигъри җанлы
Булырга бик телибез.

*Хәкимова Гөлинә, Иске Кырлай төп мәктәбенең 6 сыйныф укучысы*

## Директорларның республика семинары

17 нче февральдән 19 нчы февральгә кадәр мәктәбебездә Кукмара һәм Арча мәктәпләре директорлары өчен "Укыту-тәрбия процессында яңа инновацион технологияләр куллану" темасына семинар булып узды. Кунаклар мәктәпнең педагогик"капиталы" белән таныштылар. География укытучысы Гаффарова Дамира Вакилевна милли-региональ компонентны исәпкә алып төзелгән электрон дәреслеген тәкъдим итте. Химия-биология укытучысы Маннанова Лилия Равилевна имтиханнарга әзерләнгәндә Яндекс-ЕГЭ дан ничек файдалану турында информация бирде. Укытучылар Закирова Л.А., Гыйбадуллина З.Ш., Шигабиева Л.Р., Потехина Л. А. үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Информатика укытучысы Гыйбадуллин Илназ Зөфәрович үткәргән мастер-класс кунакларны бигрәк тә җәлеп итте. "Укыту-тәрбия процессына яңа иннвацион технологияләрне кертү тәҗрибәсеннән" темасы астында үткән семинарның соңгы көнендә мәктәп Кукмара мәктәбе директорлары белән беррәттән үз районыбыз директорларын, мәгариф идарәсе начальнигы Дәүләтбаев З.М.ны, "Арча хәбәрләре" корреспонденты Фәттахов И.С.ны кабул итте. Мәктәп директоры Ибрагимов Алмаз Ринатович мәктәпнең "Электронное образование" сайты аша эшләнгән проекты белән таныштырды. Эшлекле уеннар аша кунаклар бу проектның уңай һәм тискәре якларын бәяләделәр. Ата-аналар, җәмәгатьчелек, укытучылар фикере тыңланылды. Мәктәбебезгә килгән кунаклар бу төр яңалыктан канәгать булып киттеләр.

*Л.Ә. Закирова, Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең укыту эшләре буенча директор урынбасары*

## Төбәкара семинар

Биектау районы Ямаширмә урта гомуми белем мәктәбе базасында 24 нче февральдә "ФДББС шартларында туган телне укытуда нәтиҗәләргә ирешү юллары" темасына татар теле һәм әдәбияты укытучыларының төбәкара түгәрәк өстәл утырышы булды. Чарада ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидат, доцент, ТР ның Атказанган укытучысы, Каюм Насыйри премиясе лауреаты Шәмсетдинова Рәсимә Равил кызы; филология фәннәре кандидаты, тел белеме кафедрасы доценты Сәгъдиева Рамилә Камил кызы; филология фәннәре кандидаты, тел белеме кафедрасы доценты Хадиева Гөлфия Камил кызы; "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты директоры Валеева Даимә Харис кызы катнашты. Безнең Арча районыннан да татар теле һәм әдәбияты укытучылары чакырылган иде. Түгәрәк өстәл утырышында Ямаширмә урта мәктәбе укытучылары татар халкының онытыла башлаган "Бәби юындыру", "Чәй әзерләү" йолалары һәм калфак чигү буенча мастер-класслар күрсәтте. Мәктәп укучылары туган төбәккә багышланган концерт номерлары белән чыгыш ясады. Укытучылар үзләрен борчыган мәсьәләләргә тукталдылар, татар телен укыту өчен кирәкле методик әсбаплар турында сөйләштеләр. Укучыларга милли тәрбия бирүдә татар теле һәм әдәбияты дәресләренең әһәмияте, бүгенге заман шартларында сыйфатлы белем бирү турында фикер алыштылар. Семинар эшлекле шартларда үтте.

*Л.М. Габдрахманова., Казанбаш төп мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## 46 нчы республикакүләм чаңгы туризмы буенча ярыш

Татарстанда яшьләр арасында туризмны үстерү һәм сәламәтлекне ныгыту макса - тыннан, 20-22 февраль көннәрендә Яшел Үзән шәһәрендә Татарстан беренчелегенә чаңгы туризмы буенча ярышлар узды. Арча районыннан "Укучылар сарае" командасы составында мәктәбебез укучылары Сибагатуллина И., Сибагатуллина Г., Галимуллина Г., Солтанова С. катнаштылар. Кызларыбыз шәхси беренчелектә 2,3 урыннарны яуладылар. Нәтиҗәдә Арча районы командасы 3 призлы урынга лаек булды. Тренерлар Р.Р.Нәбиуллин, И.Х.Шакировка рәхмәтебезне бел -дерәбез, әукучыларыбызга яңа уңышлар теләп калабыз.

*Ф.Н. Гайнанова, Лесхоз урта мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*



# Үлемне җиңгән шагыйрь

## Мәңге үлмәс, Муса, синең җыр!

Казанбаш төп мәктәбендә 15 нче февральдә Муса Җәлилнең 110 еллыгына бәйрәм кичәсе үткәрелде. Кичәдә Муса Җәлилнең фашистлар тоткынлыгында фидакарь батырлыгы турында укучылар чыгыш ясады. 6 нчы класс укучысы Җәлил сүзләренә язылган "Җырларым" ны башкарды. 5-9 нчы класс укучыларыннан ике команда Муса Җәлил иҗатына багышланган КВН бәйгесендә катнашты, залдагы тамашачылар белән викторина уены үткәрелде. КВН да катнашучыларга истәлекле бүләкләр тапшырылды. Муса Җәлилнең тормыш юлын, аның иҗатын без татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә өйрәнәбез. Кичә барышында без Муса Җәлилнең батырлык үрнәге икәнлегенә тагын да ныграк инандык. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең Ватан алдында тугрылыгы, фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклыгы, батырлыгы безнең өчен һәрвакыт үрнәк булып торсын. Илебез күгә һәрчак аяз булсын, сугышлар кабатланмасын!

*Әүхәдиева Зәлифә, 8 сыйныф укучысы*



**Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 110 ел**



## Муса Җәлил халык күңелендә яши

Бүгенге көнгә кадәр җирлегебез тарихында бу бөек шәхесне өйрәнү һәм зурлап бәйрәм итү – укучыларга төрле җаваплы чыгышлар әзерләтү кызыл җеп булып 1966 нчы елдан, ягъни Муса Җәлилнең 60 еллык юбилей көннәреннән үк сузылып килгән, халкым хәтере шуны исбатлый.

Ә миңа исә III республика фәнни- гамәли конференциясенә катнашып, үз төбәгемнең Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен өйрәнүнең дәвамлы эшчәнлеге турында горурланып сөйләү бәхете елмайды. Кайбер табышларым белән уртаклашасым килә.

1950 -1982 нче елларда мәктәбебездә татар теле һәм әдәбияты укыткан мөхтәрәм ветеран укытучы Борһанова Гөлҗәүһәр Борһан кызы миңа күпләргә яңалык булырдай бер очрашу хакында сөйләде:

- Мин 1970 нче елда Әгерҗе районы Иж –Бубый авылында Муса Җәлил белән тоткынлыкта булган Мәхмүт абый Башаров белән очраштым. Ул безнең мәктәптә тарих фәне укыткан Камкина Гайшә апаның тормыш иптәше иде. Әсирлек язмышының иң аянычлы яклары турында сөйләтте. 1945 нче елда әсирлектән азат ителсә дә, әсир булганы өчен тагын ун ел төрмәдә утырырга туры килә аңа.

Соры стеналар, цементтан катырылган өстәл-урындыклар... Тоткынлыктагы газаплы тормыштан да горурланырлык мизгелләр алган бит ул. Бу - оптимистик рух биреп торучы Муса Җәлилне күрү. Ул миллләттәше Муса Җәлилнең оста оештыручы булуын, Ватанына тугрылыклы, көчле ихтыярлы, батыр йөрәкле чын кеше булуын горурланып сөйләде.

*Разил Шәфеев, Урта Пошалым төп мәктәбенең 9 сыйныф укучысы*

## Герой шагыйрь Муса Җәлилгә

Муса абый синең шигырьләрең  
Илһам бирә минем күңелгә,  
Синең гомерең безгә маяк булыр,  
Синең даның яңгырар гомергә.  
Курку белмәс бөек шагыйребез,  
Эләксә дә дошман кулына,  
Батыр көрәшә ул һәм шигырьләр яза,  
Тап төшерми тормыш юлына.  
Патриот шагыйрь озак газапланган,  
Ләкин үз Ватанын сатмаган.  
Гомерен халкы өчен бүләк итеп,  
Көрәшченең антын аклаган.  
Синең бөек исемең һәрвакытта  
Хөрмәт белән искә алына.  
Синең гомерең якты маяк булды,  
110 еллыгында итәбез тантана.

*Илүсә Шагисламова, Урта Пошалым төп мәктәбенең 7 сыйныф укучысы*